КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 декабрь г.Казань № 1435

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибе турында» 2017 ел, 21 сентябрь, 705 нче карары белән расланган Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибе турында» 2017 ел, 21 сентябрь, 705 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 7 июль, 648 нче, 2022 ел, 14 октябрь, 1100 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибен яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (карарга теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә планлы күрсәткечләр формалаштыру тәртибенә кушымта (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 29 декабрь, 1435 нче карары редакциясендә)

Хезмәт хакын түләүгә җибәрелә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре (казна учреждениеләреннән тыш) тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр өлеше, шул исәптән максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш

| Т/с | Ведомство буйсынуында Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре булган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе исеме | Хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган керемнәр өлеше, процент |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы | |
| 1.1. | дәүләт бюджет һәм автоном сәламәтлек саклау учреждениеләре - югары технологияле медицина ярдәме үзәкләре | кимендә 70 |
| 1.2. | югары технологияле медицина ярдәме үзәкләреннән тыш, дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениеләре | кимендә 75 |
| 2. | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | кимендә 75 |
| 3. | Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы | кимендә 75 |
| 4. | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы | кимендә 75 |
| 5. | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | кимендә 75 |
| 6. | Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы | кимендә 75 |
| 7. | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы | кимендә 75 |
| 8. | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы | кимендә 75 |
| 9. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы | кимендә 75 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 10. | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать байлыклары министрлыгы | кимендә 75 |
| 11. | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы | кимендә 75 |
| 12. | Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты | кимендә 75 |
| 13. | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты | кимендә 75 |
| 14. | Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты | кимендә 75 |
| 15. | «Татарстан Республикасында ягулык-энергетика ресурслары сыйфатын һәм рациональ файдалануны тәэмин итү идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе | кимендә 75 |
| 16. | «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе | кимендә 75 |
| 17. | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе | кимендә 75 |
| 18. | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы* | кимендә 50 |
| 19. | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы* | кимендә 50 |
| 20. | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы * | кимендә 50 |
| 21. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе* | кимендә 50 |
| 22. | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы* | кимендә 50 |
| 23. | «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт учреждениесе* | кимендә 50 |

*Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәр исәбенә чираттагы финанс елына хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган керемнәр фаразы чираттагы финанс елына хезмәт хакын арттыру индексларын кулланып агымдагы финанс елына фараздан түбән булмаган күләмдә формалаша.

Муниципаль учреждениеләр тарафыннан хезмәт хакын түләүгә җибәрелә торган, шул исәптән максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрнең тәкъдим ителә торган өлеше

| Т/с | Тармак исеме | Хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган керемнәр өлеше, процент |
|---|---|---|
| 1. | Мәгариф | кимендә 75 |
| 2. | Яшьләр сәясәте | кимендә 75 |
| 3. | Башка тармаклар | кимендә 75 |
| 4. | Мәдәният* | кимендә 50 |
| 5. | Спорт* | кимендә 50 |

*Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәр исәбенә чираттагы финанс елына хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган керемнәр фаразы чираттагы финанс елына хезмәт хакын арттыру индексларын кулланып агымдагы финанс елына фараздан түбән булмаган күләмдә формалаша.

---